

Уважаемые гости! Вы находитесь на странице, где подробно представлена история МБОУ Евлаштауская СОШ и Мешабашской НОШ. Мы не стали переводить на русский язык текст истории наших школ. Надеемся, видеоролики помогут вам ознакомиться с жизнью школ в разные годы.

{swf}evlashtay|800|600|0{/swf}

Татар халкы vзенен укымышлылыгы, мәгърифәткә омтылышы элек-электән vк аерылып торган.Kvп мәктәп-мәдрәсәләрдә дин сабаклары белән, доньяви фәннәр дә укытылган.

Әхмәтжанова Рабига апа Ахунжан кызы(1907 нче елда Явлаштау авылында туган) истәлекләреннән: " Мин беләә башлаганда, 1914 нче еллардан безнен авылда Мохәммәткамал мулла һәм Вафия абыстайлар яши иде.Алар шушы авылныкы. Мулла абзый мәдрәсәдә малайларны, ә абыстай оендә кызларны дин сабагына укытты. Мин 8-9 яшьләремдә Вафия абыстайга йореп дин сабагын укыдым.Кышларын 1-2 кисәк утын агачы да кыстырып бара идек.

Мина 10 яшьләрдә, 1917 нче елда Мохәммәткамал мулла һәм абыстай вафат булдылар. Аларнын оныклар, нәселләре Саба авылында Камалов Хабибрахман(инде вафат), Шәмәрдәндә Камалова Роза, анын улы Дамир Исхаков, авылда Ганиева Сәлимәләр яши. Авылда муллалык итvче булмагач, 1918 нче елларда Наласа авылыннан Габделбәр мулла һәм Нәкыя абыстайны китерделәр. Хәзерге мәчет бинасы каршында (Гыйльметдинов Нияз хужалыгында) мәдрәсәдә мулла абзый малайларны, ә абыстай оендә кызларны укытты. Мин Нәкыя абыстайда 2 ел укыдым. Минем белән Мәгъсvмә, Бибизакирә, Назифа исемле кызлар укыды, алар vзләре дә соныннан абыстайлык иттеләр. Аларнын, мулла һәм абыстайларнын, 5 баласы бар иде. Уллары Габделбасыйр зур укыган кеше булган, ә Хәсән Боек Ватан сугышында һәлак булган.

1924 нче елда авылда янгын чыгып мәчет һәм кvп йортлар янган. Габделбәр мулла һәр хужалыктан 2шәр бvрәнә жыеп, халык ярдәме белән яна мәчет торгызуда зур коч куйды.

1928-1929 нчы уку елында мәдрәсә йортында башлангыч мәктәп ачыла. Анда Шекше авылыннан Мобәрәков Хәким дигән егет 1нче сыйныф укучыларын укыта. 1931-1932 нче елларда мәчет ябыла. Габделбәр мулла белән Нәкыя абыстайны 5 балалары белән авылдан сорәләр. Алар Свердловск шәһәренә урнашып, шунда вафат булалар. Кызлары авылга кайткалап та йориләр. Балаларны мәчеттә дә, мулла оендә дә (Гайфетдинова Мослимә йорты) укыттылар.

Авылда колхоз гаражы янында Зариф байнын тире иләv заводы бар иде. Улы булмагач, анын якын туганы Касыйм заводка хужа булып калды. 1931 нче елда аны авылдан кугач, завод бинасын колхозга алдылар. Анын аскы этажы таштан, ә осте агачтан иде. Аскы этажында ашханә-урманчылык ашханәсе, ә остә-янкорма тозеп, башлангыч мәктәп булды. Бу мәктәптә башта Мобәрәков Хәким, аннан Әхәтова Рәшидә директор булып эшләделәр.Укытучылар Сәрдек авылыннан Гали Әскәр улы, Зәйнәп исемле хатын-кыз, Вәлиев Габдерахман, Насыйров Әзхан исемле кешеләр эшләде. 1942-1946 нчы елларда Сәетгәрәева Разыя башлангыч классларда укытты."

Сугыштан сон, 1945-1946 нчы уку елында Явлаштау башлангыч мәктәбенә рус теле укытучысы итеп Галимжанова Масфура Фатыйх кызы (1927 нче елда Килдебәк авылында туган) эшкә жибәрелә.

Анын сойләvләренә тукталып vтик: " Зав.РОНО иптәш Степанов иде. Мин килгәндә 1- 4 классллы башлангыч мәктәптә барлыгы 124 укучы укый. Мәктәп элекеге байларнын тире эшкәртv заводы булган. Ул ике катлы, аскы каты таштан, ә икенче каты агачтан эшләнгән иде. Мәктәп vзе иске, тәрәзәләре дә кечкенә генә, идәннәре бик начар. Класслар саен мич чыгарылган иде. Шунда утын ягып класслар жылытылалар иде.

Класс бvлмәләре кысан, ә балалар саны ишле. Мин килгәндә мәктәптә 4 укытучы укыта. Алар Әхәтова Рәшидә апа, Вәлиева Хәтирә, Сәетгәрәева Разия һәм Шытсу авылыннан килгән кыз Нажияләр эшлиләр иде. 1945-1946 нчы уку елыннан сон кыскартулар булды. Вәлиева Хәтирә һәм Сәетгәрәева Разияләрне эштән алдылар. Алар урынына Исмагыйлова Нажия һәм Самарина Әлифә апалар килде. Шушы чорда кичке мәктәпләр оешып китте. Кичке мәктәптә укучылар vзләренә белемне керосин лампасы яктысында алды.

Аннан сон, колхоз бер бура сатып алып, аны класс иттеләр. 1950-1951 нче уку елында башлангыч мәктәпне жидееллык мәктәпкә әйләндерделәр. Башта 5 нче класслар гына була. Безнен мәктәптә Мишәбаш һәм Иштуган балалары да белем алды. Ул вакытта бернинди дә транспорт юк. Укучылар жәяу йореп белем алалар. Биш-алты ел чамасы укып йоргәннән сон гына Иштуган авылынын vзендә мәктәп ачыла, аннары белемнәрен шунда дәвам иттеләр.

Сугыштан сонгы авыр еллар. Башлангыч класс укучыларына бер дәфтәрне икегә кисеп булеп бирдек.Кара савытларын vзләре белән йортәләр. Ручкаларны манып язасы иде. Балаларнын осләренә киемнәре юк, булганнары бик начар, аяк киемнәре юк, ялан аяк килvчеләре дә бар.

Кар яугач, укуларын ташлаучылар да булды. Укуларын ташламасыннар очен, аларга кием табу жаен эзли идек. Шекше авылында булган балалар йортыннан списать ителгән киемнәрен алып укытырга туры килде.Алар мона бик тә соенәләр иде",- дип искә алды авыр елларны Масфура апа.

Әлеге мәктәпнен ул заманда шулай ике катлы салынуы югарыда эшләvче хезмәткәрләрне дә хәтта ки аптыраашта калдыра. Мирза Исмагилович әйтvенчә: " Минем мәктәпләрдә йоргәнем бар иде, ләкин әлегә кадәр икенче катка килеп кереп, беренче катка тошкән юк иде", - ди ул, шаяртып. Чыннан да, мәктәпкә тышкы яктан икенче катка керәсен, ә аннан беренче катка, ягъни таш белән эшләнгән жир астына тошәсен, анда

да сыйныф бvлмәләре урнаштырылган була.

Үз чоры очен әлеге мәктәпнен дә унайлылыклары булган. Ашханә, хезмәт бvлмәләре дә vз урынын алган.

Укуга килгәндә исә укучыларнын ботен коче укуда булырга тиеш була. Әлеге заман очен сыйныфтан-сыйныфка кvчерми калу vзенчәлеге хас. Укуга бик югары таләпләр куелган. Укучыларга уку белән беррәттән әти-әнигә йорт эшләрендә дә булышырга кирәк булган. Укучыларнын бәлки кочләре дә житеп бетмәгәндер, шуна кvрә кvчми калу очраклары да кvзәтелгән.

Балаларга тагы зур таләпләрнен берсе, укучыларнын язуларына игътибар итv. Укучыларнын язу каләмнәре 11, 12, 17, 19 номерлы гына булырга тиеш була. Басымны укучылар дорес язарга ойрәнергә тиеш була.

1957-1958 нче уку елларында мәктәпләрдә тере почмак оештырылган. Анда йорт куяннары асрарга кирәклеге турында әйтелә. Куяннарны карау укытучылар остенә йокләнелә.Куянчылык олкәсендә унышлы гына эшләр алып барыла.

Тәрбия эшләре план буенча алып барыла. Пионерлар белән эш унышлы гына бара.Торле бәйрәмнәр vткәрелә. 1 нче майда демонстрациягә чыгалар.

1962 нче елда Александров Яков директор вакытында кирпечтән яна мәктәп бинасына нигез салына.

1964-1965 уку елында директор Шәймуллин Мохәммәт вакытында мәктәп тозелеп бетә.1965 елнын февраль аенда берничә класс шунда кvчә, әлегә мәктәпнен яртысы гына олгергән була. 1965-1966 нчы уку елында тулысы белән яна мәктәптә укытыла башлый. Балалар саны 192 була.Ул мәктәптә 8 сыйныф, бер укытучылар бvлмәсе һәм коридордан бvленеп алынган директор бvлмәсе була. Бу мәктәптә директор булып Шәймуллин М.М, 10 ел хезмәт итә. Балаларга 10 укытучы белем бирә. 3 техник хезмәткәр мәктәпнен чисталыгын саклый.

Мәктәп янында хезмәт дәресләрен vткәрv очен мастерской, ягъни остаханә оеша. Остаханә ашханә ролен дә vтәп тора. Монда балаларнын тамакларын бераз гына туйдыру максатыннан чәй кайнатыла.Укучыларга икешәр шакмак шикәр оләшеп чыгалар, ипине ойләреннән алып киләләр.

1974-77 уку елларында мәктәп директоры вазыйфасын Нургаязов Фәргать Нургаяз улы башкара.Ул коридорны бvлеп алып укучылар очен буфет ача.

1977-1983 уку елларында Фәхретдинов Раиф Имам улы директор була. Шушы берничә ел эчендә Раиф Имамиевич ашханә тозетvгә һәм балалар очен мәктәпнен интернатын ачуга ирешә. Ашханәдә пешекче булып Шаехова Голчирә хезмәт итә.

Хезмәт дәресләре Ахатов Валириан Каюмович житәкчелегендә vтә. Ул агач белән эшләv алымнарын тошендерә.

1983-1984 уку елында мәктәп директоры Хужина Вәсилә Йосыф кызы була.

1983-1985 уку елларында мәктәп директоры итеп монарчы Жори мәктәбе завучы Сахапов Рафик Имам улы билгеләнә.Ул тирән белемле, таләпчән, яналыкка омтылучы житәкче була

1985-1989 уку елларында Явлаштау тугызъеллык мәктәбе директоры Кәшипов Ростәм Әнвәр улы була.

1990-1993 уку елларында Имамиев Венер Янбакович Явлаштау мәктәбенә директор итеп билгеләнә.

1993-1999 уку елларында Гыйльмуллин Илнур Васил улы мәктәп директоры

вазыйфаларын башкара

1999 елдан Явлаштау тулы булмаган урта мәктәбе директоры итеп Гыйбадуллин Золфәт Фоат улы билгеләнә. Яшь кенә булуына карамастан житәкче ботен кочен куеп эшли башлый.

2000-2001 уку елында алдагы елларда тозелә башлаган ике катлы яна мәктәп сафка баса. Ин беренче булып шушы елны 10 нчы сыйныф укучыларына белем бирелә башлый. Мәктәптә сыйныф бvлмәләре, ашханә дә барлык унайлыклары белән эшләнелгән була. Мәктәптә компьютер классы оеша.

2001-2002 уку елында Явлаштау мәктәбе урта мәктәп булып оешып китә.

2005-2006 уку елында Явлаштау урта мәктәбендә 21 могаллим яшь буынга белем бирә. Шулар арасында I һәм II категориягә ия укытучылар да шактый. Коллектив vзара тату булып, бер-берсенен тәжрибәсен уртаклашып эшли.

Бvгенге кондә мәктәптә 24 могәллим һәм 7 техник хезмәткәр vзләренен тырыш хезмәтләрен куя. 3 укытучы әлегә декрет ялында.

Мишәбаш башлангыч мәктәбе



1890 нчы еллар тирәсендә Мишәбаш авылына Кукмара районынын Ядегәр дигән авылыннан Котдус исемле мулла килгән. Алар карчыгы Таибә белән vз ойләрендә балалар укытканнар. Мулланын ое ике катлы булган, мал-туар асрап торганнар. Укырга теләгән балалар гына килгәннәр. Алар хужанын мал асларын тазартканнар, мал ойләренен мичена якканнар, һәрберсе кон саен ике-оч агач утын алып килгән. Идәнгә тезелеп утырып укыганнар, кvп кенә догаларны яттан ойрәнгәннәр. Ә язарга ойрәнмәгәннәр. Бераз сонрак эскәмияләр ясап, шуна утырып укый башлаганнар. Жомга коннәрендә сәдакага берәр ипи яки акча алып килә торган булганнар. Yзләренен дә ике балалары- Хәйдәр исемле уллары, Разия исемле кызлары булган. Котдус мулла Комар

арларын моселман диненә чыгарган. Ул шунын очен 1911 еллар тирәсендә каторгага жибәрелгән. Котдус мулла каторгадан кайткач ( 1915-1916 нчы еллар) авырып вафат булган. Ул vлгәч, хатыны Таибә Ядегәр мулласына киявгә чыккан. Аларны революциядән сон Оренбургка жибәргәннәр.Котдус мулладан сон Кәшемир мулласынын малае Фазулла килгән. Ул да хатыны белән бергә укыткан. Ә хатыны Әсмабикә Дусай мулласынын кызы булган. Болар, заманына кvрә, бик белемле кешеләр булганнар. Авылда нинди буш йорт булса, балаларны шунда укытканнар. 1929 елда авылда коточкыч зур янгын чыга ( май ае). Кvп йортлар янып бетә. Шушы янгыннан сон Фазулла муллалар Магнитогорскига кvчеп киткәннәр.1932 елны Явлаштаунын Касыйм бай йортын кvчереп, ике катлы мәктәп итеп салганнар. Тәрәзәләре зур, класслары иркен, якты, жылы коридоры булган. Бу мәктәптә Фәхретдинов Фәләхи, керәшен кызы Нажия укыткан.Район мәгариф бvлегеннән алынган мәгълvматлар буенча, ул елларда тvбәндәге укытучылар да укыткан:Шакиров ( 1934) (жәя эчендә эшкә билгеләнv вакыты), Газизова Бикә (1938), Багаветдинова М.(1939), Борисов Иван (1939), Хажиева Роза (1939), Ганиева Сәкинә (1940), Гарипов Зариф(1943), Хажиева Разия (1940), Сәетгәрәев Ислам (1945)1939 елнын 28 /12 сеннән 1942 елнын 29/3 кадәр vзебезнен авыл кешесе Әхәтов Каюм Әхәт улы эшли.1942 елнын 31 /8 нан Фәхретдинова Мәрьям апа билгеләнә. 1943 елнын 31 августыннан 1947 елнын 25 августына кадәр Мишәбаш башлангыч мәктәбендә Мәрьям апа vзенен бертуган сенлесе- Сара апа белән укыткан. 1948 елны мәктәпкә укытучы итеп Мамадыш районыннан Галиев Миннәхмәт билгеләнә.1955 елда Фәхретдинова Мәрьям янына Арча педагогия училищесын тәмамлап, Килдебәк кызы Хәсәнова Фәния килә һәм ул 1958 елга кадәр эшли. 1956 елда мәчет бинасын кvчереп матур гына мәктәп салалар.

1958 елда Мишәбаш авылына агроном итеп гаиләсе белән Шакиров Мәхмvт жибәрелә. Анын хатыны Дания укытучы була. Ул шул ук елда эшкә керешә. Ә Хәсәнова Фәния Мингәргә жибәрелә. 1967 елда Мәрьям апа лаеклы ялга китә. Анын урынына Әхәтов Валериан абый кереп эшли башлый. 1970 елда аны райкомга эшкә алалар. Мәктәптә 3 класска бер генә укытучы- Шакирова Дания генә кала. 1980 елда Дания апа лаеклы ялга китә. Шулай булса да яшь укытучы-Ярмисва Марзия апа белән ул vзенен эш тәжрибәсе белән уртаклашып, 1983 елга кадәр эшли. 1985 елны Марзия Зиннуровна ире белән Кибәхужага китә. 1987 елда Мишәбаш башлангыч мәктәбенә АПУ дан ике кыз – Хазиева (Шакирова) Рафига , Минкабирова (Фазыйлова) Фәйрvзә кайта Алар шушы авылга тормышка чыгып, әле дә булса укучыларга белем бирvләрен дәвам итәләр . Мәктәптә укучылар саны артуын искә алып, 1994 елда АПУ ны бетергән егет Шакиров Булатны да монда эшкә билгелиләр.Укучыларнын тагын да артуын кvздә тотып мәктәбебезгә 4 нче укытучы– Гыйльметдинова Фәридә Бәдегетдиновна билгеләнә. Туктарга тормышка чыгып китv сәбәпле, 2003 елда ул мәктәптән китә.Хәзерге вакытта мәктәптә калган шушы 3 укытучы белем һәм тәрбия бирә, ә 2011 елда Сәрдә башлангыч мәктәбе бетерелv сәбәпле, ул мәктәп укытучысы Галимуллина Ләйсән Ренат кызы да Мишәбашка эшкә билгеләнә. Шулай итеп бvген Мишәбаш башлангыч мәктәбендә 4 укытучы эшли. Мәктәп турында сез Шакиров Булат Мәхмvт улынын шәхси сайты ннан танышып белә аласыз.




{swf}meshabash_shola1|800|600|0{/swf}

2016 ел 1сентябрь - Мишәбаш башлангыч мәктәбе ябылды. Балалар Явлаштау урта мәктәбендә укый башлады.

2017 ел, гыйнвар - Мәктәп бинасына "Тюльпан" балалар бакчасы кvчте.